

Кибет киштәләрендә уенчыкларнын ниндие генә юк?! Әмма барысы да кирәклеме, файдалымы? Белгечләр балаларнын психикасына зыян салучы курчак-роботларны сатудан гомумән алып ташларга тәкъдим иткән. Уенчыкнын куркынычмы-юкмы икәнен махсус экспертиза ярдәмендә тикшерергә жыеналар. Замана курчакларынын  кайсысын сайларга кирәктер.
Кибет киштәсендәге матур гына курчаклар белән бергә, куркыныч курчак-машиналар тулып ята. Бvген сабыйга теге яки бу “юаткыч” сатып алганда, анын сыйфатына ул кадәр vк игътибар да ититәргә кирәк.       Кvбрәк тышкы кыяфәте борчу уята. Курчакнын кvзләре усал тvгелме, аю баласы котны очыра торган тавыш чыгарып кычкырмыймы... Кыскасы, кибеттә уенчык сайлап алу очен шактый тырышырга туры килә.
Евразия икътисад берлегендә әлеге мәсьәләне тамырдан хәл итәргә тәкъдим иткәннәр. Алар балаларнын психикасына зыян салучы уенчыкларга бәйле закон кабул итәргә кушкан. Алга таба һәр уенчык махсус экспертиза тикшерve узарга һәм белгечләр тарафыннан унай бәя алган очракта гына кибет киштәсенә озатыла башларга момкин. Тыелган курчак-машина саткан очен штраф та каралган. Кvп кенә илләр, шул исәптән Россия әлеге тәкъдимне хуплаган да инде.
Балалар очен сатыла торган товарларга игътибарны арттырунын кирәклеге турында кvптәннән сойләшәләр. Хәтерләсәгез, узган ел ахырында кайбер тvрәләр киштәдәге уенчыкларга “ярый” яки “ярамый” дигән тамга сугып чыгарга да кинәш иткән иде. Бу эш белән шогыльләнv очен махсус комиссия тозергә тәкъдим иттеләр. Тик яналыкка сатучылар каршы чыкты. Кара “моһер” сугылган курчакны сатып алырга теләvчеләр кимеячәк, димәк, табыш та югала. Узган елдан бирле кvпме вакыт vтте, комиссия дә юк, киштәдәге уенчыкларда тамгалар да кvренми. Бу юлы балалар товарларын кибеткә барып житкәнче vк энә кvзе аша vткәрмәкчеләр. Закон проекты әзерли башлаганнар инде. Бvген уенчыклар житештерv олкәсендә мәжбvри дәvләт стандартлары юк, алар кинәш рәвешендә генә тәкъдим ителә икән. Ә куркыныч уенчыклар белән уйнаучы малай-кызлар арасында агрессив, куркак сабыйлар саны бермә-бер артты, ди белгечләр.

Руфина, яшь ана:
- Кызыма уенчык сайлар очен кибет киштәләре арасында йоргәндә, балачагымны искә тошерәм. Без яраткан уенчыкларнын барысы да сатыла бит бvген! Киштәдә

курчакларның ниндие генә юк! Балага уенчык сатып алганчы, сабыйның холык vзенчәлекләренә игътибар итәргә кирәк, диләр психологлар. Нарасый чынбарлыкны кискен кабул итә икән, димәк, усал карашлы курчаклар, аждаһага охшаган роботлардан баш тартыгыз, дигән кинәшне белгечләр бирәләр. Югыйсә, бала тонлә куркып уяна башларга да момкин, диләр. Шуна колак салырга онытмыйк.

Н.Хәлил